Татар тарихының төрле чорларында татар мәгарифе үсешен дөнья диннәренең әхлакый нормалары һәм кануннары, шулай ук татарлар борынгы заманнардан ук аралашып яшәгән Кытай империясе, Һиндстан, Урта Азия, Иран, гарәп дәүләтләре халыкларының тәрбия өлкәсендәге карашлары, укыту һәм тәрбия системалары йогынтысыннан аерып карау мөмкин түгел. Ислам мәгарифенең тәэсире аеруча көчле була. VII гасыр ахырында, борынгы төркиләр арасында ислам дине тарала башлау белән, гыйбадәтханәләр каршында дини тәрбия һәм белем мәктәпләре ачыла [1: 28]. Ислам дине белән бергә, гарәп язуы һәм гарәп телендә әдәбият, көнчыгыш педагогларының хезмәтләре тарала башлый. Төрки каганлыкта, көнчыгыш дини белем бирү системасындагы кебек үк, укыту эше дини белемле остазларга йөкләнә. Хан сарае каршында эшләгән мәктәпләрне төрки аксөякләр арасында белемле булуның зур мәртәбә саналуын раслаган фактор буларак күрсәтергә мөмкин. Төркиләр, үз илләрендә белем алу белән канәгатьләнмичә, чит илләрдә дә укыганнар. Йолыг тәгин һәм гаскәр башлыгы, ханнарның киңәшчесе Таньюкукның, мәсәлән, Кытайда гыйлем эстәве билгеле. Кытайда белем алу шул заман өчен иң югары һәм мактаулы, дәрәҗәле саналган [2: 60]. Мәгариф өлкәсендәге мондый багланышлар халкыбыз, аның тәрбия, белем бирү системасы турындагы мәгълүматның дөньякүләм таралуына китергән.

Борынгы төрки чор традицияләре Идел буендагы Болгар дәүләте төзелгәннән соң да дәвам итә: болгар мәгарифе гомумислам мәгарифе йогынтысында үсә. Гарәп әлифбасы болгарларның язуы буларак кабул ителү Болгарның халыкара дәрәҗәсе тагын да күтәрелүгә, бигрәк тә Көнчыгыш Гарәп дәүләтләре, Иран белән сәүдә, икътисади, мәдәни мөнәсәбәтләр ныгуга сәбәп була. Бу дәвердә Идел Болгары атаклы фән һәм гыйлем үзәгенә әверелә. Дин һәм ислам әдәпләрен өйрәтер өчен, Багдадтан махсус галимнәр, белгечләр чакырып кайтарыла [3: 142]. Болгарда ислам дөньясының төрле почмакларыннан килгән атаклы галимнәр белем биргән (мәсәлән, тарихта шундыйларның берсе – Мәккәдән килеп Болгарда мәдрәсә ачкан Сөләйман Хуҗа турында билгеле) [4: 78]. Бу чорда башлангыч белем мәктәпләрендә, башка ислам дәүләтләрендәгечә, гарәп, фарсы телләре, Коръән һәм хәдис өйрәтелгән. Гарәп һәм фарсы телләре халыкның укымышлы катлауларында икенче әдәби тел хезмәтен үтәгән [5: 34]. Дини белем белән беррәттән, мәдрәсәләрдә дөньяви фәннәрдән дә мәгълүмат бирелгән. Дәүләтнең астрономия, медицина, тарих буенча үз галимнәре барлыкка килгән [6: 7]. Болгар укымышлылары арасында медицина гыйлеменә ия булган кешеләр аеруча дәрәҗәле саналган.

Болгарлар, үз мәктәпләреннән тыш, көнчыгыштагы шул заманның иң дәрәҗәле мәгариф һәм дин үзәкләре – Бохара, Сәмәркand,

Газнә, Нишапур, Бәлх, Багдад, Мәрвтәнең атаклы галимнәреннән белем алырга тырышканнар [4: 77]. Бу аларга Көнчыгыш мәдәниятен һәм фәнни казанышларын үзләштерүгә юл ачкан. Укымышлыларның бер өлеше, илләренә кире әйләнеп кайтып, укытучылык яки фәнни эшчәнлекләрен дәвам иткән. Мисал өчен, бертуган Таҗетдин һәм Хәсән ибн Юнысларның Гыйрактагы Мосыл, Борһанетдин әл-Болгариның Нишапур мәдрәсәсендә белем алганнан соң, туган илләренә кайтып, фәнни хезмәтләр һәм башка галимнәрнең хезмәтләренә шәрехләр язулары билгеле [7: 30].

Бу чорда телләр өйрәнүгә игътибар арту күрше дәүләтләр белән бәйләнешләрнең мөһимлеген һәм аларның ныгуын күрсәткән ачык мисал булып тора. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы герое Йосыфның, мәсәлән, күп һөнәрләр үзләштерүе һәм 72 телне белүе мәгълүм. Чит телләрне белү, башка илләр белән сәүдә, дипломатик бәйләнешләрне үстерүдән тыш, алардагы фәнни һәм мәдәни казанышларны кабул итәргә мөмкинлек биргән. Әмма чит илләр мәгарифе традицияләре болгарлар тарафыннан һәрвакытта да иҗади үзләштерелгән, аларның белем һәм тәрбия системасы нигезендә халык педагогикасы яткан.

Шәһәр һәм дала, утрак һәм күчмә мәдәниятләр үзара килешеп яшәүгә нигезләнгән Алтын Урда дәүләтендә мәдәни тормыш, нигездә, шәһәр шартларында үсә. Алтын Урда дәүләте белән Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләре арасындагы тыгыз бәйләнешләр, тормышның башка өлкәләре белән беррәттән, мәгариф өлкәсендә дә чагылыш таба. Г.Дәүләтшин билгеләгәнчә, Алтын Урда галимнәре, шәех һәм казыйлары арасында Мисырга барып белем алу һәм, киресенчә, Мисыр һәм Сүрия мәдрәсәләренә барып дәресләр бирү тәҗрибәсе нык таралган була. Гомумән алганда, бу чорда әлеге илләр арасында мәгариф бәйләнешләре бик көчле була [8: 275-276]. Алтын Урда мәдрәсәләрендә Урта Азия, Көнчыгыш һәм гарәп илләреннән килгән остазларның да укытуы билгеле [9: 163]. Урда ханнары, башка өлкәләрдән шагыйрь һәм галимнәрне сарайларына китертеп, үзләренә мәдхияләр яздыртканнар.

Казан ханлыгы чорында мәгариф үсешендә элеккеге традицияләр дәвам иттерелеп, хөкүмәт һәм вакыф акчаларына күпләп мәктәп һәм мәдрәсәләр ачыла, эре дини, мәдәни-мәгърифәт үзәкләре барлыкка килә (Казан, Болгар, Биләр). Казан ханлыгындагы югары белем биргән «мәдрәсә-и галия»ләрдә ислам дөньясының төрле төбәкләреннән килгән дәрәҗәле, танылган галимнәр укыта. Иң атаклы мәдрәсәләрнең берсе булган Кол Шәриф мәдрәсәсендә, мәсәлән, башка фәннәр белән беррәттән, фарсы теле дә өйрәтелә. Казан ханнары арасында сарайларына төрки дөньяга танылган шагыйрьләр, галимнәр, фикер ияләрен җыю традициясе тарала. Китапханәләр төзү, фәнни басмалар туплау иң мәртәбәле, абруйлы эшләрдән санала. Ш. Мәрҗани, халык телендә йөргән сүзләргә таянып, бу чорда Казан шәһәрендә бик зур һәм яхшы китапханә булуы, әмма аның, кызганычка каршы, руслар Казанны алганнан соң яндырылып юк ителүе турында яза [3: 158].

Алдагы чорлардагы кебек үк, Казан ханлыгында да укымышлылар арасында күп телләр белү зур мәртәбәләрдән исәпләнеп, аеруча гарәп, фарсы телләре киң кулланылышта була. Бу вакытта гади халыкның күпчелеге укый-яза белгән. Хәтта һөнәрчеләрнең дә бер өлеше гарәп һәм фарсы телен яхшы белгән; бу турыда шул чорга караган кабер ташлары һәм башка язулы предметлар сөйли [4: 77].

Казан ханлыгы җимерелгәннән соң, күп гасырлар дәвамында урнашкан традицияләр юк ителә, мәгариф өлкәсендә моңарчы күрелмәгән аерымлану башлана, чит илләр белән бәйләнешләргә чик куела. Хәрабәләр хәленә китерелгән мәчет-мәдрәсәләр белән беррәттән, Казан ханлыгы чорында тупланган гаять бай китапханәләр, борынгы язмалар һәм дәреслекләр яндырыла, акыл ияләре, галимнәр юк ителә, халык мәгарифтән читләштерелә, Ш.Мәрҗани сүзләре белән әйткәндә, «гыйлем-мәгариф бик түбәнәя» [3: 159]. Шулай итеп, гасырлар буенча үскән һәм камилләшә барган уку-укыту системасы юкка чыгарыла. Татарларның бер өлеше, Дагыстан, Кырым һәм Төркиягә качып, шундагы мәдрәсәләрдә белем алырга мәҗбүр була, күпмедер вакыттан соң аларның күбесе кире әйләнеп кайта [10: 238]. Бу чорда милли мәдәният һәм мәгариф системасы, алдагы чорлардан аермалы буларак, нигездә, авыл шартларында сакланып килә.

Патша хакимиятенең Урта Азия һәм Көнчыгыш илләрендә колониаль сәясәтен җәелдерү өчен, татар телен белүче дәүләт кешеләре әзерләү ихтыяҗы туа. 1758 елда шул максатларны күздә тотып ачылган Казан

гимназиясендә рус, татар һәм европа телләре белән беррәттән гарәп, фарсы, калмык, монгол, кытай һ.б. телләр өйрәнелә [11: 5]. Патша хөкүмәте, чит телләрне яхшы белүләре сәбәпле, татар галимнәрен көнчыгыш илләре белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыруда илче һәм тылмач буларак файдалана [12: 14]. Шул ук вакытта көнчыгыш илләре белән дипломатик язышуның татар телендә алып барылуы да билгеле [5: 33].

XVII гасыр ахырында белемгә сусаган татар яшьләре Урта Азия мәдрәсәләренә барып белем эстәгәннәр. Ш.Мәрҗани язганча, Мәвараэннәһергә, беренчеләрдән булып, Казан өязеннән Юныс ахун, мулла Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети һ.б. юнәлә [3: 233-234]. Бохарада белем алучылар арасында Оренбургның беренче мөфтие Мөхәммәтҗан Хөсәеновның бабасы Мансур да була. Туган иленә кайтканнан соң, ул зур гына мәдрәсә ача һәм аңа мөдирлек итә.

XVIII гасырның икенче яртысында татарларда дини белем бирү системасының яңадан торгызылуында Дагыстан галимнәренең роле зур була. Анда белем алып кайткан татар имамнары Урта Идел буенда укытуның Дагыстан моделен (хокук, хәдис өйрәтү, риторика, гарәп телен укыту) кертә башлыйлар [1: 94]. Ш.Мәрҗани Дагыстан голямаларыннан, аерым алганда, Мөхәммәт бине әд-Дагыстанидан, белем алган татар яшьләре турында (алар арасында Мансур бине әл-Борындыкый да бар) кайбер мәгълүматлар язып калдыра [3: 211].

XVIII гасырның соңгы чирегендә, татарларның Урта Азия белән сәүдә бәйләнешләре ныгыгач, дини белем алырга теләгән яшьләр акрынлап Бохарага юл ала башлыйлар[1]. Ватаннарына кайткач, алар, Урта Азия уку йортлары үрнәгендә, ислам теологиясен укытуга нигезләнгән мәдрәсәләр ачалар. XVIII гасырның 70 елларында Казанда Ахун һәм Апанай, 1780 елда Әмирхановлар йортында мәдрәсәләр ачыла. XVIII йөз ахырына инде һәрбер зур авылда диярлек мәдрәсә була. Мәдрәсәләрдә Бохара моделе нигезендә фарсы теле һәм әдәбияты аеруча киң өйрәнелә башлый. Фарсы һәм гарәп телләрен нигезле үзләштерүгә корылган укыту программалары татар мәдрәсәләренең Урта Азия белем бирү системасы белән үрелеп үсүенә китергән. Шулай итеп, Россиянең эчке губерналарында Урта Азия дини белем бирү системасы урнаша.

XVIII–XIX гасыр чикләрендә татарлар арасында мәгърифәтчелек идеяләренең тарала башлавы иҗтимагый, аерым алганда, педагогик фикер үсешенең яңа бер баскычы булып тора [1: 120]. 1804 елда Казанда университет ачылу, аның, башка юнәлешләр белән беррәттән, шәрыкны, шуның бер өлеше буларак, татар телен өйрәнү үзәгенә әверелүе, Азия, соңрак университет басмаханәсе барлыкка килү – болар барысы да уку-укыту өлкәсенә уңай йогынты ясый (1802 елда биредә дини һәм педагогик характердагы 5 китап дөнья күрә) [11: 7]. Казан университеты белән хезмәттәшлек иткән галимнәрдән И.Хәлфин татар, төрек, гарәп, фарсы телләрен укытуга басым ясаса, М.Мәхмүдов, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри һ.б.ның педагогик эшчәнлегендә мәгариф өлкәсендә багланышлар мәсьәләсе, беренче чиратта, русларга татар телен укыту, татарларга рус телен һәм дөньяви фәннәрне укыту юнәлешендә күзаллана.

XIX гасырның икенче яртысында мәгърифәтчелек хәрәкәте җәмгыятьнең барлык катламнарында да чагылыш таба, мәгърифәтчелек-реформаторлык идеяләре алга сөрелә (Ш.Мәрҗани, Х.Фәезханов, К.Насыйри, Ш.Күлтәси һ.б.). Урта Азия мәдрәсәләрендә кулланылган схоластик уку-укыту системасы күпләрне канәгатьләндермәгәнлектән, татар яшьләре Каһирә, Искәндәрия һәм Истамбул уку йортларына юнәлә башлыйлар [1: 120].

Җәдитчелек хәрәкәтенең беренче адымнары XIX гасыр башында ук ясалса да, аның чын мәгънәсендә тормышка ашырылуы Исмәгыйль Гаспралы эшчәнлеге белән дә бәйле. Җәдитчелек – ул мәгариф өлкәсендә мәдәниятара һәм милләтара багланышларның иң ачык мисалларының берсе, чөнки аның нигезендә рус, Европа һәм төрек белем бирү системалары ята. Шулай итеп, җәдитчелек төрле ил һәм халыклар мәгарифендәге иң алдынгы, заманча фикер һәм технологияләрне өйрәнүгә һәм татар мәгарифенә яраклаштыруга китергән.

XX гасыр башы – татар мәгарифе тарихына яңа дәреслекләр, яңа авторлар, яңа идеяләр белән кереп калган чор. Яңа ысулга нигезләнеп эшләнгән дәреслекләр татарларны гына түгел, ә

[1] Билгеле булганча, атаклы мәгърифәтче галим Шиһабетдин Мәрҗани дә 5 ел дәвамында Бохарада укый, аннан соң, белемен тирәнәйтү максаты белән Сәмаркандка юнәлә. Ике елдан соң кабат Бохарага кайтып, «Мир гарәб» мәдрәсәсендә укуын дәвам итә.

бәлки башка кардәш халыкларны укытуда да киң кулланылган. Урта Азиядә 1905-1906 елларда Казан татарлары тарафыннан ачылган җәдит мәктәпләрендә җирле халыкларны татар педагоглары Һ.Максуди, Х.Зәбири дәреслекләре буенча укыталар. 1910 елның ахырында Урта Азиядә яшәүче сартлар арасында (үзбәк, кыргыз, казах) мөгаллимлек итүне тыю турында карар дөнья күрүгә карамастан, татар мөгаллимнәренең гыйлем тарату эшчәнлекләрен дәвам итәргә тырышулары билгеле [13: 46, 47, 49, 77, 80]. Гомумән алганда, Октябрь революциясенә кадәр Урта Азиядә, казах далаларында яшәүче кардәш халыкларга аң-белем таратуда татар яшьләренең роле зур була [14: 219]. Татар шәкертләренең ислам динен ныгытуга – мөселман йолаларын урнаштыруга керткән өлешләре дә игътибарга лаек.

Октябрь революциясеннән соңгы чорда да Урта Азия халыкларына белем бирүдә татар укытучылары зур эш башкара. Мәсәлән, кызлар өчен ачылган махсус мәктәпләрдә мөгаллимәләрнең күпчелеге татар хатын-кызлары булуы билгеле. Күренекле татар педагоглары З.Бурнашева, З.Баимбетова, М.Якупова, М.Бәхтияроваларның җирле халыклар арасында педагогик кадрлар әзерләүгә керткән өлешенә галимнәр югары бәя бирә [15].

Билгеле булганча, бу вакытта татар мәгарифе гомумсовет белем бирү закончалыклары нигезендә үсеш ала; милли традицион белем бирү системасы тамырдан үзгәртеп корыла: мөселман дөньясы белән ике арада булган элеккеге элемтәләр юкка чыгарыла, милли мәгариф системасы яңа совет принципларына таянып үзгәртелә. Укыту һәм белем бирүдә яңа юллар эзләү мәгариф өлкәсенә Европа һәм Америка педагогикаларында кулланылган методларның күпләп кертелүенә китерә. 1920 елларда актив кулланылышта булган Дальтон-план, комплекслар системасы, бригада-лаборатор, проектлар методы, индивидуаль-төркемле укыту, грамотага өйрәтүдә бөтен сүзләр Америка методы һ.б. шундыйлар [16: 96-133]. Димәк, совет уку-укыту системасы, бер яктан, ябык булып, чит элементларга урын калдырмаска омтылса, икенче яктан, ул яңа юллар эзләү барышында башка илләрнең педагогик мирасына нигезләнеп үсә.

Татар теленең дәүләт теле буларак кабул ителүе, барлык уку йортларында татар теле укытылу, югары уку йортларында татар телендә белем алу мөмкинлеге бирелү, «институтларны татарлаштыру» сәясәте тормышка ашырылу, татар телен укыту методикасының фәнни нигезләргә салынуы, уку йортларының һәр баскычы – мәктәптән алып югары уку йортларына кадәр татар телендә дәреслекләр һәм башка уку әсбаплары белән тәэмин ителү (күбесе рус теленнән тәрҗемә рәвешендә) һ.б. 1920 елларның XX гасыр мәгарифе тарихында үзенчәлекле урын тотуы турында сөйли. Ләкин шуңа игътибар итәргә кирәк: бу чорда татар мәктәпләре милли рухта түгел, ә бәлки татар телендә белем бирүче гадәти гомумбелем бирү мәктәпләре буларак кына үсеш ала [17: 401]. Милли мәгариф системалары, шул исәптән татарларныкы да, Россия мәгарифендәге бердәм кануннарга буйсындырыла. 1938 елда «Милли республикалар һәм өлкәләрдәге мәктәпләрдә мәҗбүри рәвештә рус телен укыту» турындагы дәүләт законы кабул ителү милли мәгариф үсешенә шулай ук тискәре йогынты ясый.

1958-1985 еллар тарихка, гомумән алганда, татар мәгарифе үсешендә торгынлык чоры буларак кереп кала. Мәгарифне реформалаштыруда беренче адымнар ясалса да [18: 272], милли мәгариф үсеше өчен мөмкинлекләр тудырылмады. Рус теленең өстенлекле хәлдә булуы татар мәктәбенең үсешен тоткарлау сәбәпле, милли телдә белем бирү оешмалары, нигездә, авылларда гына сакланып кала[2]. Татар мәктәбе совет (рус) мәктәбенең татар телле варианты буларак яши.

Советлар берлеге Мәгариф системасының коммунистик җәмгыять таләпләренә туры килерлек шәхес, рус телендә аралашучы «бердәм совет халкы» тәрбияләүне, мәктәп һәм тормыш арасында бәйләнеш урнаштыруны төп максат иткән тенденцияләре татар мәктәбе эшчәнлегендә дә чагылыш таба. Бу чор М.Мәхмүтов нигезләгән проблемалы укыту, гыйлем бирүдә новаторлык, белем һәм тәрбия бирүдә эзләнү элементларын куллану кебек тенденцияләр белән билгеләнә. Ләкин, белгәнебезчә, алар татар милли мәгарифе үсешенә китерми: татар мәктәпләренең саны кими, бөтен ил күләмендә эшләп килгән татар педагогия техникумнары ябыла һ.б. Мәгариф

[2] 1980 елларда Казан шәһәрендә татар телендә белем бирүче мәктәпләрнең саны бары тик 2 генә була (аның да берсе – республика күләмендәге интернат-мәктәп).

өлкәсендә багланышлар берьяклы рус (совет) мәктәбе казанышларын үзләштерүгә кайтып кала.

XX гасырның 90 еллары – Татар мәгарифен система буларак торгызу дәвере – Россия күләмендә күп санлы татар мәктәпләре, гимназияләре ачылу, югары уку йортларында татар бүлекләре һәм төркемнәре барлыкка килү, дәреслекләр язылу, «Татар мәгарифе үсеше», «Татар телендә югары белем бирү» концепцияләре эшләнү һәм кабул ителү һ.б. белән характерлана. Бу чорда татар мәгарифе өлкәсендә халыкара бәйләнешләр дә яңа баскычка күтәрелә. Халыкара дәрәҗәгә күтәрелү мөмкинлеге күзалланган (югары белемне Оксфордта дәвам итү), Россия һәм чит илләр югары белем бирү системалары белән бәйләнештә торган, милли мохитле, күп белгечлекләр буенча тирән белемнәр бирүче иң эре фәнни-методик үзәк, дөнья буйлап таралган татар милләтенең интеллектуаль, фәнни, мәдәни һәм рухи потенциалын саклау һәм үстерү максатын куйган Татар милли университетының концепциясе эшләнү һәм аның эшчәнлеге, татар-төрек лицейлары ачылу, татар яшьләрен Төркия һәм башка мөселман илләрендә укыту, укытучыларның осталыгын чит илләрдә камилләштерү (стажировка), студентлар һәм мәктәп укучыларын алмашу программаларын тормышка ашыру мөмкинлеге барлыкка килү дә әлеге чорның үзенчәлекләре булып тора. Соңрак Болонья процессына кушылу, белем бирүдә Сингапур моделе, Халыкара бакалавриат системалары кулланыла башлау, уку-укытуга Монтессори, Вальфдорф, С.Френе педагогик системалары кертелү һ.б. мәгариф өлкәсендәге багланышларны активлаштыра. Болонья процессына кушылу нәтиҗәсендә, югары белем алуда ике баскычлы система кабул ителә, магистратура булдырыла, татар филологларына башка ил университетлары белән уртак магистратура программалары әзерләүгә юл ачыла, магистрлар өчен стажировкалар оештырыла, Бөтенроссия студентлар олимпиадасы үткәрелә башлый, халыкара программаларда һәм проектларда катнашу, чит ил университетларыннан галимнәр чакыру мөмкинлеге барлыкка килә һ.б.

Укучыларның уйлау, фикерләү, анализлау сәләтен, кызыксынучанлыкларын үстерүгә юнәлтелгән Сингапур технологиясе дә татар мәгарифенә йогынты ясаган төп факторларның берсенә әверелә. Татар мәктәбендә, татар теле һәм әдәбиятын укытуда актив кулланыла торган әлеге модель, белгечләр билгеләгәнчә, укучыларның сәләтен, индивидуаль үсешен генә тәэмин итеп калмый, ә заман өчен аеруча актуаль булган үзара ярдәмләшү, хезмәттәшлек, үзбәя, үзара контроль кебек таләпләрнең үтәлешенә һәм үсешенә ярдәм итә. Соңгы елларда үткәрелгән халыкара тикшеренүләрдә Россия мәгарифенең теориягә йөз тотуы, нигездә, академик характерда булуы ассызыклану сәбәпле, хәзерге мәгариф системасы алдына гамәли юнәлешкә игътибарны арттыру бурычы куела. Сингапур технологиясе исә шул максатны тормышка ашыруда үтемле чараларның берсе буларак карала.

Шулай итеп, алда санап үтелгән үзенчәлекләр хәзерге чорда татар мәгарифенең үсешен, аның халыкара бәйләнешен билгелиләр.

Мәгариф, мәдәният өлкәсендәге багланышлар мәсьәләсенә килгәндә, тагын уртак тарихка, мәдәнияткә, дингә, уртак тамырларга ия булган төрки халыклар арасындагы традицияләрне барлау һәм үстерү юнәлешенә тукталу мөһим. Казан шәһәренең Төрки дөньяның мәдәни башкаласы буларак игълан ителүе, гуманитар проблемаларга өстенлек биреп, уртак тарихи һәм мәдәни мирасны барлау һәм өйрәнү белән шөгыльләнгән Төрки дәүләтләр фәннәр академияләренең берлеге төзелү, бергәлек идеясе, галимнәр карашынча, беренче чиратта, фәнни алгарыш өчен нигез булып тора. Шуңа күрә төрки халыкларның тарихын, мәдәниятен бергәләп өйрәнү, фәнни потенциалны уртак зур проектларга туплауның әһәмияте гаять зур [19]. 2014 елда «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» Дәүләт программасы нигезендә Казан федераль университетының Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты каршында К.Насыйри институты эшли башлау, аның Мәскәү һәм Казахстанның Астана шәһәрләрендә махсус үзәкләре ачылуның да татар халкын, телен, мәдәниятен дөньякүләм танытуда, төрки халыклар арасында мөнәсәбәтләрне ныгытуда роле, һичшиксез, зур.

Хәзерге чорда төрки халыкларның әхлак-тәрбиягә караган фикерләрен, тәҗрибәләрен, традицияләрен туплаган уртак педагогик мирасын өйрәнү, тугандаш-кардәш халыкларның бу өлкәдәге рухи байлыкларын

бер-берләренә таныту һәм аларны педагогик процесста файдалану мөмкинлеген тудыру шулай ук иң актуаль мәсьәләләрнең берсе булып тора. 2013 елда Халыкара Төрки академия тарафыннан әзерләп бастырылган «Түркілік тәрбие» антологиясе шул максатларны күз алдында тота [20].

Басма авторларының берсе буларак , татар халкының тәрбия мирасын башка төрки халыкларга җиткерү эшен башкарган галим Х.Миңнегулов билгеләгәнчә, антологиянең төп өлеше тәрбия процессының һәм, гомумән, инсан яшәешенең үзәк мәсьәләләрен үз эченә алган иң әһәмиятле берничә зур бүлектән (рубрикадан) гыйбарәт (Бишек тәрбиясе; Гадәт-йолалар; Әхлак тәрбиясе; Патриотик, ирлек тәрбиясе; Хезмәт тәрбиясе; Акыл тәрбиясе; Дини тәрбия; Эстетик тәрбия; Матурлыкка, зифалыкка күнектерү аша тәрбияләү; Физик һәм экологик тәрбия һ.б.); әлеге уникаль хезмәт алты төрки кавем – азәрбайҗан, казах, кыргыз, татар, төрек, үзбәк халыкларының педагогик мирасын бербөтен итеп күз алдына китерергә мөмкинлек бирә [21: 112]. Китапта татарның тәрбия мирасы М.Гафури, Г.Тукай, Г.Ибраһимов әсәрләре, халык педагогикасының иң матур үрнәкләре, шулай ук гыйльми хезмәтләр аша тәкъдим ителә.

Бу басманың әһәмияте, безнең карашка, иң беренче чиратта, кардәш төрки халыклар арасындагы багланышларны тагын да көчәйтү, бер тамырдан чыккан, бинибая зур уртак мираска ия булган төрки дөньяны бергә туплау, җиһан күләмендә танытудан гыйбарәт. Шул ук вакытта, әлеге хезмәт төрки халыкларның бай тәҗрибәсен, рухи-мәдәни кыйммәтләрен мәгариф, тәрбия өлкәсендә файдалану мөмкинлеген тудыручы зур потенциал булып тора.

Кардәш халыклар арасындагы бәйләнешләрне ныгытуда аларның телләрен үзләштерү һәм аның методикасын эшләүнең дә әһәмияте зур. Кызганычка каршы, бу юнәлеш әлегә күләгәдә кала бирә. Уңай мисалларның берсе төсендә Халыкара Төрки академия галимнәре тарафыннан казах телен кардәш тел буларак өйрәтүгә багышланган хезмәтне аерып күрсәтергә мөмкин [22]. Бу урында шулай ук төрки халыкларның әдәби мирасын туплау һәм өйрәнүнең әһәмияте турында да әйтеп узу мөһим [23].

Шулай итеп, бүгенге көндә татар мәгарифе алдындагы төп бурычларның берсе булып милли рухны, күп гасырлык кыйммәтләребезне саклаган хәлдә, бөтендөнья белем бирү системалары үсешенең төп тенденцияләрен өйрәнү һәм аларны белем бирүдә уңышлы файдалану, заман таләпләренә җавап бирерлек шәхес тәрбияләү бурычы тора. Әлеге бурычны тормышка ашыру юлында күп телләр үзләштерү мөмкинлеген тудыру иң әһәмиятле юнәлешләрдән санала. Дәүләт телләре белән беррәттән чит телләрне өйрәнү, тел компетенциясен табигый һәм гуманитар белемнәр үзләштерүдә, Татарстан Республикасынының чит ил һәм дәүләтләр белән икътисади һәм фәнни-техник бәйләнешләрен ныгытуда файдалану мөмкинлеген тудыру дәүләт сәясәтендәге төп, нигез мәсьәләләрнең берсенә әверелде. Моңа «2015–2020 елларда Татарстан Республикасында милли мәгариф системасын үстерү концепциясе» проектында да[3] игътибар ителгән. Анда шулай ук Татарстан Республикасының күпмилләтле (полиэтник) булуына, төрле милләтләрнең милли-мәдәни һәм мәгариф өлкәсендәге ихтыяҗларын мөмкин кадәр тулырак канәгатьләндерү бурычын хәл итүгә басым ясала. Шуңа күрә республикада яшәүче милләтләрнең мәдәни, сәнгать, педагогик тәҗрибәсен укыту һәм тәрбияви максатларда куллану аеруча мөһим.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: бүгенге мәгариф системасыннан һәм заман укытучысыннан мөмкин кадәр сыгылмалы булу, ягъни дөнья педагогикасы казанышларын кабул итәргә әзер булып, шул ук вакытта аларны милли тәрбия һәм белем бирүдәге төп кыйммәтләр белән дөрес итеп үреп алып бара белү таләп ителә.

**Әдәбият**


1. Татар педагогик фикере антологиясе. Т.1. / ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. Казан: Татар. кит. нәшр, 2014. 407 б.
2. *Давлетшин Г.* Культура Древних тюрков. Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. 64 с.
3. *Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) / төз. Ә.Н.Хәйруллин. Казан: Татар.кит.нәшр., 1989. 415 б.
4. *Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш.* Булгарская цивилизация на Волге. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 112 с.


[3] Әлеге документ әзерлек процессында.

5. *Абилов Ш.Ш.* Урта гасыр татар әдәбияты // Татар әдәбияты тарихы. Т.1. Казан: Татар. кит. нәшр, 1984. 566 б.
6. *Ханбиков Я.И.* Основные направления в развитии педагогической мысли татарского народа в XI - XX вв.: автореф. дис. ... д-ра пед.наук. М., 1968. 27 с.
7. *Шарафутдинов З.Т.* Педагогическое пространство татарского народа. Казань: 2000. 180 с.
8. *Давлетшин Г.М.* Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (Истоки, становление и развитие). Казань: 2004. 431 с.
9. *Абилов Ш.Ш.* Социаль тормыш, культура һәм әдәби мохит // Татар әдәбияты тарихы. 6 томда. Т.1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. 566 б.
10. *Фәхретдинов Р.* Болгар вә Казан төрекләре / төз., кереш сүз, искәрмәләр авт. Ә.Н.Хәйруллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 287 б.
11. *Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И.* История педагогики Татарстана. Казань, 1998. 306 с.
12. *Ханбиков Я.И.* История развития педагогической мысли татарского народа. Казань, 1975. 162 с.
13. *Бобровников Н.А.* Русско-туземные училища, мектебы и медресы Средней Азии: путевые заметки. С.-П.: Сенатская тип., 1913. 90 с.
14. *Мортазина Л.Р.* Татар педагогик фикерен өйрәнүнең теоретик һәм методологик нигезләре («Татар педагогик фикере антологиясе»н төзү тәҗрибәсе нигезендә) // TATARICA. 2014. №1(2). 209-222 б.
15. *Биктемирова Т., Хамитбаева Н.* Татарки-просветительницы // www.tataroved.ru/institut/center/ (соңгы карау: 20.06.2016).
16. *Муртазина Л.Р.* Педагогическая деятельность ликбезов в 20 – 40-е годы XX столетия (на примере Республики Татарстан): дис. … кан.пед.наук. Казань, 2003. 184 с.
17. *Шакиров Р.В.* Казанская педагогическая школа во второй половине XX века. Казань, 1999. 528 с.
18. *Шакиров Р.В.* Школа и общество: Системно-концептуальный анализ реформ образования в России в XX в. Казань: 1997. 621 с.
19. Татарстан Фәннәр академиясе президенты М.Салахов белән әңгәмә // www.azatliq.org/content/article/27113924.html/ (соңгы карау: 10.03.2016).
20. «Түркілік тәрбие» антологиясы. Алматы: Интеллсервис, 2013. 1004 б.
21. *Миңнегулов Х.* Төрки дөнья хәзинәләре // Казан утлары. № 12. 2013. 108-113 б.
22. *Қадашева Қ., Асанова У.О., Ашикбаева Б.Г.* Қазақ тілін туыс тіл ретінде оқыту әдістемесі (Түркі тілдерінде сөйлейтіндер үшін). Алматы: «Кантана-пресс», 2012. 400 с.
23. Корни наши едины: из сокровищницы тюркских литератур. Казань: Магариф-Вакыт, 2014. 311 с.

---

# ВЗАИМООТНОШЕНИЯ ТАТАР С ДРУГИМИ СТРАНАМИ И НАРОДАМИ В СФЕРЕ ОБРАЗОВАНИЯ: ИСТОРИЯ И СОВРЕМЕННОСТЬ

**Ляля Раисовна Муртазина,**
Институт истории имени Ш.Марджани АН РТ,
Россия, 420014, г.Казань, Кремль, подъезд 5,
lyalyamur@mail.ru.

В статье рассматривается история взаимоотношений татар с другими народами и странами в области образования как одна из важнейших тенденций в развитии татарского просвещения в разные периоды исторического развития – начиная от древнетюркского и до наших дней. На основе многочисленной литературы и источников по теме исследования автор приходит к выводу, что межкультурные связи проявляются прежде всего в форме обмена опытом, использования передовых достижений других народов, взаимовлияния на педагогические процессы. Автором предпринята попытка определения роли ислама в развитии татарского просвещения, а также говорится о необходимости применения педагогического опыта родственных народов.

**Ключевые слова:** татарское просвещение, мектебы-медресе, зарубежные страны, взаимоотношения в области просвещения, тюркское просвещение, просвещение булгарского периода, общеисламское просвещение, традиции Золотой Орды, Казанское ханство, просветительство, джадидизм, европейское просвещение, общетюркское педагогическое наследие, родственные народы.